ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

06.03.2019 241

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү өчен агымдагы елның 1 сентябренә 6 яшь һәм 6 ай тулмаган һәм 8 яшьтән өлкәнрәк булган балаларны беренче сыйныфка кабул итүгә рөхсәт бирү тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 67 статьясындагы 1 өлеше нигезендә, Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алу өчен гражданнарны кабул итү тәртибен раслау турында» 2014 елның 22 гыйнварындагы 32 номерлы боерыгы нигезендә, гражданнарның гомуми белем алуга хокукларына дәүләт гарантияләрен тәэмин итү максатларында

КАРАР БИРӘМ:

1. Агымдагы елның 1 сентябренә 6 яшь һәм 6 ай тулмаган һәм 8 яшьтән өлкәнрәк булган балаларны Нурлат муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү оешмаларына, башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча, әлеге карарга кушымта нигезендә укырга кабул итүгә рөхсәт бирү тәртибен (алга таба-Тәртип) расларга.
2. Нурлат муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә әлеге карар белән расланган Тәртип нигезендә эш итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге башлыгына йөкләргә.

Җитәкче Л.Н. Маняпов

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының

2019 ел, 6 март, 241 нче карарына кушымта

Нурлат муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү оешмаларына башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү өчен агымдагы елның 1 сентябренә 6 яшь һәм 6 ай тулмаган һәм 8 яшьтән өлкәнрәк булган балаларны беренче сыйныфка кабул итүгә рөхсәт бирү тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Агымдагы елның 1 сентябренә 6 яшь һәм 6 ай тулмаган һәм 8 яшьтән өлкәнрәк булган балаларны Нурлат муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү оешмаларына башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укырга кабул итүгә рөхсәт бирүнең чын тәртибе (алга таба - Тәртип) «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча гражданнарны кабул итү тәртибен раслау турында» 2014 елның 22 гыйнварындагы 32 номерлы боерыгы, РФ баш дәүләт санитар табибының 2010 елның 29 декабрендәге 189 номерлы карары белән расланган гомуми белем бирү учреждениеләрендә белем бирү шартларына һәм укытуны оештыру шартларына санитар-эпидемиологик таләпләр, эпидемиология кагыйдәләре һәм нормативлары (СанПиН 2.4.2821-10) нигезендә эшләнгән һәм ТР Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба — Башкарма комитет) тарафыннан Нурлат муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү оешмаларына (алга таба - муниципаль гомуми белем бирү оешмалары) муниципаль гомуми белем бирү программалары буенча 6 яшь һәм 6 ай тулган балаларны һәм 8 яшьтән өлкәнрәк балаларны башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укыту өчен рөхсәт бирү кагыйдәләрен билгели.

1.2. Агымдагы елның 1 сентябренә 6 яшь һәм 6 ай тулмаган яки 8 яшьтән өлкәнрәк булган балаларны беренче сыйныфка кабул итү Башкарма комитет рөхсәте нигезендә гамәлгә ашырыла.

1.3. Гомуми белем бирү оешмалары тарафыннан 1 сентябрьгә кадәр 6 яшь тә 6 айга җитмәгән балаларны укыту, әлеге яшьтәге балалар өчен белем бирү учреждениеләрендә укыту шартларына барлык санитар-эпидемиологик кагыйдәләр һәм нормативларны үтәп үткәрелә. Әгәр гомуми белем бирү оешмалары күрсәтелгән таләпләрне үтәүне тәэмин итми икән, ата-аналар муниципаль гомуми белем бирү оешмасында укыту өчен булдырылган шартларда укуга язмача ризалык бирергә хокуклы.

2.Агымдагы елның 1 сентябренә 6 яшь һәм 6 ай тулмаган һәм 8 яшьтән өлкәнрәк булган балаларны гомуми белем бирү оешмаларының 1 нче сыйныфына кабул итүгә рөхсәт бирүне оештыру.

2.1.Агымдагы елның 1 сентябренә 6 яшь һәм 6 ай тулмаган яки 8 яшьтән өлкәнрәк булган балаларны муниципаль мәгариф оешмасының беренче классына

кабул итүгә рөхсәт алу өчен ата-аналар (законлы вәкилләр) район Башкарма комитеты җитәкчесенә 1 нче кушымта нигезендә гариза тапшыра. Алты яшь тә алты ай тулмаган балаларны һәм 8 яшьтән өлкәнрәк балаларны гомуми белем бирү учреждениеләренә кабул итү мәсьәләсен үз вакытында хәл итү максатларында, уку елы башланырга 10 көннән дә соңга калмыйча гаризаны Башкарма комитетка бирергә тәкъдим ителә.

2.2. Гариза белән бергә ата ана (законлы вәкил) түбәндәге документларны бирә:

а) гариза бирүченең шәхесен раслаучы документ;

б) бала туу турында таныклык;

в) баланың законлы вәкиле вәкаләтләрен раслаучы документ;

г) чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар Россия Федерациясендә булу хокукын раслаучы документ тапшыралар;

д) баланың гомуми белем бирү оешмасында белем алуга психологик әзерлеген раслый торган документ (психиатрдан белешмә, яки ПМПК уңай бәяләмәсе, беренче сыйныф укучысының башлангыч дәрәҗәсендә өйрәнү нәтиҗәләре буенча аналитик белешмә);

е) яше җитмәгән килеш уку өчен медицина ягыннан каршы күрсәтмәләренең булмавын раслаучы документ (сәламәтлек саклау учреждениесе тарафыннан бирелә торган форма буенча);

ж) медицина күрсәткечләре ягыннан бераз соңрак яшьтә укуны раслаучы документ (сәламәтлек саклау учреждениесе тарафыннан бирелә торган форма буенча);

Баланың ата-аналары (законлы вәкилләре) үз теләге белән башка документларны тапшырырга хокуклы.

2.3. 2 пунктның а), б), в) пунктчаларында күрсәтелгән документлар кире кайтарылырга тиешлеләре оригиналларда һәм район Башкарма комитетында кала торганнары ксерокопияләрдә тапшырыла.

2.4.Гариза һәм документларга таләпләр:

а) гамәлдәге законнар белән билгеләнгән таләпләргә туры килү,

б) документ текстын ручка белән яки компьютор ярдәмендә ачык аңлаешлы язу;

в) мөрәҗәгать итүченең фамилиясен, исемен һәм атасының исемен, аның яшәү урынын (урнашу урыны), телефонын кыскартуларсыз күрсәтү;

г) документларда төзәтүләр булмау.

2.5. Документлар кабул итүдән баш тарту өчен нигез:

1) баланың ата-анасы (законлы вәкиле) булмаган граждан мөрәҗәгать иткәндә;

2) Әлеге тәртипнең 2.3, 2.4 пунктларында күрсәтелгән документларны тапшырмау;

3) әлеге Тәртипнең 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны рәсмиләштерүгә карата таләпләр бозылу.

2.6. Гариза һәм документлар кабул итүне Башкарма комитетның мәгариф бүлеге (алга таба - мәгариф бүлеге) гамәлгә ашыра.

2.7. Гариза һәм тапшырылган документлар әлеге тәртипнең 2.3, 2.4, 2.5 пунктлары белән билгеләнгән критерийларга туры килмәгән очракта, мәгариф

бүлеге гариза һәм документларны кабул итүдән баш тарта, кирәкле документлар комплекты белән яңадан гариза бирү мөмкинлеге турында хәбәр итә. Гаризаны һәм теркәлгән документларны кире кайтару турындагы белешмәдә тамга куела.

2.8. Кабул ителгән гариза тапшырылган документлар белән Нурлат муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү оешмасының беренче сыйныфына башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча 1 сентябрьгә 6,6 яшькә җитмәгән балаларны һәм 8 яшьтән өлкәнрәк балаларны укыту өчен гаризалар теркәү һәм рөхсәт бирү журналында теркәлә (алга таба Журнал (әлеге тәртипкә 2 нче кушымта)).

2.9. Гаризаны теркәү датасыннан алып ике эш көне дәвамында мәгариф бүлеге агымдагы елның 1 сентябренә 6,6 яшькә җитмәгән һәм 8 яшьтән өлкәнрәк булган балаларны беренче сыйныфка кабул итүгә рөхсәт бирүгә гаризаларны карау буенча Нурлат муниципаль районы муниципаль берәмлегендә башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча (алга таба – комиссия) белем алу өчен комиссия төзи. Комиссия 3 кешедән дә ким булмаган күләмдә төзелә һәм мәгариф бүлеге башлыгы, мәгариф бүлеге белгече, башлангыч белем бирү буенча методист һәм педагог-психологны үз эченә ала.

2.10. Тапшырылган документлар нигезендә Комиссия 5 эш көне дәвамында түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

- агымдагы елның 1 сентябренә 6,6 яшькә җитмәгән һәм 8 яшьтән өлкәнрәк булган балаларны Нурлат муниципаль районы муниципаль берәмлегендә башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укыту өчен беренче сыйныфка кабул итүгә рөхсәт бирү турында;

- агымдагы елның 1 сентябренә 6,6 яшькә җитмәгән һәм 8 яшьтән өлкәнрәк булган балаларны Нурлат муниципаль районы муниципаль берәмлегендә башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укыту өчен беренче сыйныфка кабул итүгә рөхсәт бирүдән баш тарту турында.

2.11. Мәгариф бүлеге комиссия карар кабул иткән көннән 2 эш көне эчендә (тәртиптәге 3 нче кушымта) 6 яшь һәм 6 айдан кечерәк һәм 8 яшьтән өлкәнрәк булган баланың ата-анасына (законлы вәкилләренә) башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча уку өчен муниципаль гомуми белем бирү оешмасының беренче классына баланы кабул итүгә рөхсәт бирә (әлеге Тәртипнең 4 нче кушымтасы), яисә 6 яшь 6 айдан кечерәк һәм 8 яшьтән өлкәнрәк булган балаларны башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укыту өчен муниципаль гомуми белем бирү оешмасының беренче классына алудан баш тарту турында белешмә бирелә (Тәртипкә 5 нче кушымта).

2.13. 6 яшь тә 6 айдан кечерәк һәм 8 яшьтән өлкәнрәк булган баланы муниципаль гомуми белем бирү оешмасының беренче классына кабул итүгә рөхсәт бирүдән баш тарту түбәндәгеләр белән бәйле булырга мөмкин:

- баланың сәламәтлеге буенча күрсәтмәләр булу;

- әлеге Тәртипнең 2.3 пунктында күрсәтелгән баланың мәктәпкә психологик әзерлеге турында бәяләмә булмаганда;

- әлеге Тәртипнең 2.3 пунктында күрсәтелгән баланың мәктәптә белем алуга әзерлеге турында тискәре нәтиҗә булу;

- муниципаль берәмлекләрдә белем бирү процессын оештыру шартлары белән мәктәпкәчә яшьтәге балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре) ризасызлык белдерүе.

2.14. Башкарма комитет тарафыннан бирелгән 6 яшь тә 6 айдан кечерәк һәм 8 яшьтән өлкәнрәк балаларны беренче классына кабул итүгә рөхсәт нигезендә, Россия Федерациясе законнары һәм тиешле муниципаль белем бирү учреждениесендә билгеләнгән кабул итү кагыйдәләре нигезендә, Россия Федерациясе законнарына каршы килми торган өлешендә, кабул итүнең тигез шартлары принципларында, "Россия Федерациясендә мәгариф турында" 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә укырга кабул иткәндә махсус хокук (өстенлекләр) бирелгән затлардан тыш, муниципаль белем бирү учреждениесе тарафыннан югарыда күрсәтелгән балаларны беренче сыйныфка кабул итү гамәлгә ашырыла.

2.15. Башкарма комитетның агымдагы елның 1 сентябренә 6 яшь һәм 6 ай тулмаган яки 8 яшьтән өлкәнрәк булган балаларны кабул итүгә рөхсәт бирүдән баш тартуына ата-аналар (законлы вәкилләр) тарафыннан суд тәртибендә шикаять белдерелергә мөмкин.

1 нче кушымта
к Порядку выдачи разрешения
на приём в первый класс детей,
не достигших на 1 сентября
текущего года возраста 6 лет

и 6 месяцев и старше 8 лет,
на обучение по образовательным
программам начального общего
образования в муниципальные
общеобразовательные организации

Форма

ЗАЯВЛЕНИЕ
о выдаче разрешения на приём в первый класс ребёнка, не достигшего на 1 сентября текущего года возраста 6 лет и 6 месяцев и старше 8 лет, на обучение по образовательным программам начального общего образования в муниципальную общеобразовательную организацию Нурлатского муниципального района Республики Татарстан

Руководителю Исполнительного комитета
Нурлатского муниципального района Республики Татарстан
от_______________________________________________

проживающего по адресу:____________________________

контактный телефон:_____________________________

___

**ЗАЯВЛЕНИЕ**

Прошу разрешить обучение в первом классе муниципальной бюджетной образовательном учреждении

______________________________________________________________________________

(наименование МБОУ)

моего ребёнка___________________________________________________________________,

(фамилия, имя, отчество (последнее при наличии) ребенка,

______________________________________________________________________________

(дата рождения ребенка),

зарегистрированного по адресу:

_______________________________________________________________

______________________________________________________________________________

(указать адрес регистрации),

проживающего по адресу:______________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

(указать адрес фактического проживания),

которому на 01 сентября 20_____ года не исполнится 6 лет и 6 месяцев.

С условиями и организацией обучения в муниципальной общеобразовательной организации ознакомлен (а) и согласен (на).

К заявлению прилагаю следующие документы (нужное отметить - V):

Копию свидетельства о рождении ребенка;

Копию документа, подтверждающего родство заявителя (или законность представления прав ребенка);

Копия документа, подтверждающего психологическую готовность ребенка к обучению в общеобразовательной организации (справка от психиатра или положительное заключение ПМПК, аналитическая справка по итогам изучения стартового уровня будущего первоклассника );

другие документы____________________________________________________.

Выражаю своё согласие на обработку (сбор, систематизацию, накопление, хранение, уточнение (обновление, изменение), использование, распространение способами, не противоречащими закону) моих персональных данных и данных моего ребёнка.

«___» __________ 20___г. ___________/__________________
(подпись) (расшифровка подписи)

Ответ прошу дать в виде (нужное отметить - V)

почтового отправления по адресу:_______________________________________________________________;

электронного письма по e-mail:__________________________________________________________________;

лично в руки.

«___» __________ 20___г. ___________/__________________
(подпись) (расшифровка подписи)

2 нче кушымта
к Порядку выдачи разрешения
на приём в первый класс детей,
не достигших на 1 сентября
текущего года возраста 6 лет
и 6 месяцев и старше 8 лет,
на обучение по образовательным
программам начального общего

образования в муниципальные
общеобразовательные организации

Форма

**ФОРМА**
**журнала учета оформления и выдачи разрешений (отказе от выдачи разрешения) на прием в общеобразовательные учреждения, реализующие программы начального общего образования, детей в возрасте младше 6 лет и 6 месяцев или старше 8 лет**

| № п/п | Дата и входящий номер регистрации заявления | ФИО заявителя (заявителей), его адрес регистрации / фактического проживания, контактны телефон, адрес электронной почты | ФИО ребенка, дата его рождения, адрес регистрации/ фактического проживания | Наименование и адрес места нахождения общеобразовательного учреждения | Дата, номер разрешения на прием, год приема | Дата, номер мотивированного уведомления об отказе в выдаче разрешения, причины отказа | Примечания |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |

3 нче кушымта
к Порядку выдачи разрешения
на приём в первый класс детей,
не достигших на 1 сентября
текущего года возраста 6 лет
и 6 месяцев и старше 8 лет,
на обучение по образовательным
программам начального общего

образования в муниципальные
общеобразовательные организации

Форма

**РЕШЕНИЕ**
**Комиссии по приему в 1 класс детей в возрасте младше 6,5 лет или старше 8 лет**

«_____» ___________ 20__г. №_______

Комиссия по приему в 1 класс детей в возрасте младше 6,5 лет или старше 8 лет,

рассмотрев заявление гр. _______________________________________________
и прилагаемые к нему документы, установила, что:

_____________________________________________________________________________,
(фамилия, имя, отчество ребенка)

_____________________________________________________________________________,
(число, месяц, год рождения)

к обучению в школе готов/не готов (нужное подчеркнуть) и может быть/не может быть (нужное подчеркнуть) принят в 1 класс МБОУ
____________________________________________________________________________.

| № п/п | Причины выдачи отрицательного заключения | +/- |
|---|---|---|
| 1. | Наличие противопоказаний по состоянию здоровья ребенка | |
| 2. | Отсутствие заключения психолого-медико-педагогической комиссии, психиатра о готовности ребенка к обучению | |
| 3. | Отрицательное заключение психолого-медико-педагогической комиссии, психиатра о готовности ребенка к обучению | |
| 4. | Иные причины (указать, какие): | |

| №п/п | ФИО члена комиссии | Подпись |
|---|---|---|
| 1. | | |
| 2. | | |

| | | |
|---|---|---|
| 3. | | |

4 нче кушымта

к Порядку выдачи разрешения
на приём в первый класс детей,
не достигших на 1 сентября

текущего года возраста 6 лет
и 6 месяцев и старше 8 лет,
на обучение по образовательным
программам начального общего
образования в муниципальные
общеобразовательные организации

Форма

Исполнительный комитет Нурлатского муниципального района Республики Татарстан

ул.Советская, д.117, г.Нурлат, 423040 Телефон: (84345) 20610, 20614, факс 22561E-mail: Nurlat.Ispolkom@tatar.ru, сайт: nurlat.tatarstan.ru

от__________ г. №

Разрешение на приём ребёнка в первый класс муниципальной общеобразовательной организации на обучение по образовательным программам начального общего образования в возрасте младше 6 лет 6 месяцев и старше 8 лет

Уважаемый(ая) ______________________________________________________________,
(фамилия, имя, отчество (последнее при наличии) заявителя)

Исполнительный комитет Нурлатского муниципального района РТ , рассмотрев Ваше заявление, а также приложенные к нему документы, на основании заключения о психологической готовности ребенка к школьному обучению разрешает прием Вашего ребенка_____________________________________________________
(фамилия, имя, отчество (при наличии) ребенка,

___________________________________________________________________________
(дата рождения ребенка)

на обучение по образовательным программам начального общего образования в муниципальную общеобразовательную организацию_____________________________________________.
(наименование МОО)

Руководитель ___________ _________________

(подпись) (расшифровка)

5 нче кушымта
к Порядку выдачи разрешения
на приём в первый класс детей,
не достигших на 1 сентября
текущего года возраста 6 лет
и 6 месяцев и старше 8 лет,

на обучение по образовательным
программам начального общего
образования в муниципальные
общеобразовательные организации

Форма

Исполнительный комитет Нурлатского муниципального района Республики Татарстан

___

ул.Советская, д.117, г.Нурлат, 423040 Телефон: (84345) 20610, 20614, факс 22561E-mail: Nurlat.Ispolkom@tatar.ru, сайт: nurlat.tatarstan.ru

от_________г. №__________

**Уведомление**
**об отказе в выдаче разрешения на прием ребенка в первый класс муниципальной общеобразовательной организации на обучение по образовательным программам начального общего образования в возрасте младше 6 лет 6 месяцев и старше 8 лет**

Уважаемый(ая)

___,

(фамилия, имя, отчество (последнее при наличии) заявителя)

Исполнительный комитет Нурлатского муниципального района РТ , рассмотрев Ваше заявление, а также приложенные к нему документы, на основании заключения о психологической готовности ребенка к школьному обучению уведомляет об отказе в выдаче разрешения на прием Вашего ребёнка___

(фамилия, имя, отчество (последнее при наличии)ь ребёнка),

___

(дата рождения ребёнка)

на обучение по образовательным программам начального общего образования в муниципальную общеобразовательную организацию по причине

___

___

(указать причину)

Руководитель

___ ___

(подпись) (расшифровка)